РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
15.12.2021

КАРАР
№ 99

**Әтнә район Советының 04.10.2021 елдагы № 80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан чаралар үтәлешен муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елдагы № 131-ФЗ Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 27.07.2010 елдагы №190-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 елдагы № 248-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Әтнә район Советының 04.10.2021 елдагы № 80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан үтәлешен муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне кертергә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе Г.Г.Хәкимов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма комитетының
2021 елның 15 декабрендәге 99 номерлы
карарына

**Әтнә район Советының 04.10.2021 елдагы № 80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан чаралар үтәлешен муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр**

**1. V бүлекнең 40пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

**«40. Шикаятьне судка кадәр бирү тәртибе.**

31.07.2020 елдагы № 248-ФЗ Законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, тиешле муниципаль контроль төрен гамәлгә ашырганда шикаятьләрне судка кадәр бирү тәртибе кулланылмый.»

**2. 4 нче кушымтаның 2 нче пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«2. Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) индикатив күрсәткечләре исемлеге:

1) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны, яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе;

3) хисап чорында үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;

4) хисап чорында үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

5) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

6) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;

7) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

9) хисап чорында административ хокук бозулар турында кузгатылган эшләр контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

10) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

11) хисап чорында тикшерү (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

12) прокуратура органнарына контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында җибәрелгән гаризалар саны, алар буенча прокуратура органнары хисап чорында килешүдән баш тарткан;

13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

14) хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны хисап чоры ахырына, һәр риск категориясе буенча;

15) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;

16) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны, хисап чорында;

17) контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны, хисап чорында;

18) контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны, хисап чорында;

19) контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында дәгъва гаризалары саны, алар буенча игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында Карар кабул ителгән, хисап чорында;

20) дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылды һәм (яисә) юкка чыгарылды, хисап чорында.